# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Тузган торак фондын бетерү өчен максатчан кертем турында**

**1 статья.** Максатчан кертем тузган торак фондын бетерү, тузган торак кварталларын реконструкцияләү өчен өстәмә финанс ресурсларын барлыкка китерү чыганакларының берсе булып тора.

Әлеге Закон нигезендә максатчан кертем Татарстан Республикасы территориясендә эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик затлар тарафыннан кертелә.

**2 статья.** Максатчан кертем средстволары Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фондында туплана һәм тузган торак фондын бетерү, тузган торак кварталларын реконструкцияләү эшләрен финанслауга җибәрелә.

**3 статья.** Максатчан кертем реализацияләнгән продукциядән (эшләрдән, хезмәт күрсәтүләрдән) кергән акчаның кимендә бер проценты күләмендә кертелә һәм Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фондына ай саен күчерелә.

**4 статья.** Әлеге Законны куллану тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

**5 статья.** Әлеге Закон 2002 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә. Бу Закон үз көченә кергән көннән түбәндәгеләрнең үз көчләрен югалтуын танырга:

«Тузган торакны бетерү өчен максатчан салым турында» Татарстан Республикасының 1996 елның 13 июнендәге 648 нче Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 12);

«Тузган торакны бетерү өчен максатчан салым турында» Татарстан Республикасы Законына өстәмәләр кертү хакында» Татарстан

Республикасының 1997 елның 26 декабрендәге 1442 нче Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 12);

«Тузган торакны бетерү өчен максатчан салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасының 2000 елның 29 июнендәге 234 нче Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 7-8 (6);

«Тузган торакны бетерү өчен максатчан салым турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү тәртибе хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1996 елның 13 июнендәге 649 нчы карарының («Республика Татарстан», 1996, 29 июнь, № 129-130).

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 25 октябре
№ 1147